| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**30.12.2022 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3624** |
|---|---|---|

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру һәм «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 ел, 20 август, 1557 нче; 2022 ел, 17 гыйнвар, 42 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 2560 нче; 2022 ел, 14 октябрь, 2730 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм

хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен 2023 елның 1 гыйварыннан арттырырга.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазифаи окладлы күләмен 1,061 тапкыр индексацияләргә һәм 12 688 сум күләмендә билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 ел, 20 август, 1557 нче; 2022 ел, 17 гыйнвар, 42 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 2560 нче;, 2022 ел, 14 октябрь, 2730 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 4 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В. Старостин